№1. Гыйнвар, 2026



# Чишмә башы

МБГБУ “Урта Курса төп гомуми белем мәктәбе”

## Бу санда:

**27нче гыйнвар** – Ленинградны фашистлар блокадасыннан азат итүгә 80 ел – 1нче бит.

**Укучылар иҗаты** – 2нче бит.

**Шигъри тәлгәшләр** – 3нче бит.



Яңа елга аяк бастык, дуслар! 2026 ел Россиядә **“Россия халыклары бердәмлеге елы”**, Татарстанда **“Хәрби һәм хезмәт батырлыгы елы”**, ә Арчабызда исә **“Габдулла Тукай елы”** дип игълан ителде.

# ӨЧ ЕЛ ДӘВАМ ИТКӘН ТӘМУГ АЧЫСЫ...



***Ленинградны фашистлар блокадасыннан тулысынча азат итүгә 80 ел.***

Илебез тарихында халкыбыз бик тә авыр вакыйгалар кичергән чорлар булган. Бөек Ватан сугышын алсак, 26 миллион 600 мең кешенең гомере өзелгән. Бу каһәрле сугыш калдырган канлы эзләр беркайчан да онытылмаячак.



Фашист илбасарлары шәһәрне чолганышта тотканда бары бер максат куя — аны тулысынча юк итәргә. 1941 елда дошман Ленинград шәһәрен илдән аерып ала һәм аның коры җир белән бәйләнешен тулысынча өзә. Бу блокада 871 көн дәвам итә. Ленинград белән Ладога күле һәм һава юллары аша гына бәйләнешкә керә алалар.

Сугышка кадәр Ленинградта 3 миллионга якын кеше яшәсә, блокада вакытында ул 1 миллион кешесен югалта, калган 1 миллионы эвакуацияләнә. Бу елларда Төньяк башкала бөтен ил өчен батырлык үрнәге күрсәтә.

Әлеге истәлекле көн уңаеннан мәктәбебездә “Блокада икмәге” сыйныф сәгате үтте. 5-9 сыйныф укучыларына ленинградлыларның батырлыкларын сүрәтләгән “Код доступа. Матч жизни” дип исемләнгән видеофильм күрсәтелде.




# УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ

## Шигырь туа күңелдә...

Көндәлек мәшәкатьләргә чумып, без әйләнә-тирәбездәге матурлыкны да күрмибез икән бит. Көн бик суык булганга кәефем китеп, теләр-теләмәс кенә урамга чыктым. Чыксам, әкият дөньясына килеп кердеммени! Дөнья ап-ак бәскә сарылган. Кояш яктысында бәс, кар бөртекләре алтынсу төсләргә кереп җем-җем итеп ялтырый. Агачлар, урман ак мамык шәлгә бөркәнгән. Аяк атлаган саен шыгырт-шыгырт кар шыгырдый. Бу сихри дөнья мине әллә ниткән уйларга чумдырды. Күңелдә шигъри юллар туды...



***Кыш***

Өч ак атын җигеп чанасына
Кыш бабай бара узып.
Сафландырып бар дөньяны
Ак карлар кала тузып.

***Буранлы көн***

– Ни булган бу дөньяга?
Җил улый, дулый, үкерә.
– Яз килүгә диптер инде,
Буран абзый юл себерә.

***Мәрьям Гарифуллина,***
***7 нче сыйныф укучысы***

# ШИГЪРИ ТӘЛГӘШЛӘР



### *Кышкы маҗаралар*

Югары Курса - матур авыл,
Бик күп таулардан тора.
Чаңгы - чана шуганда да
Бураннар уйнап тора.

Безне буран куркытмый,
Һәмәбезнең йөзе шат.
Матур яуган йомшак кар
Битләрне итә ап – ак.

Иртән чыгып китәбез дә
Кич соң гына кайтабыз.
Авырайган чаналарны
Көч - хәл белән тартабыз.

Өй янында гаилә белән
Кыш бабай да ясадык.
Йомшак карда чума- чума
Рәхәтләнеп уйнадык.

***Габидуллина Камилә,***
***6 нчы сыйныф укучысы***

### *Табигатькә кыш килде*

Табигатькә кыш килде,
Дөнья карга төренде.
Тау шуучы балаларга
Шундый рәхәт, күңелле.

Ә бүген төнлә буран
Бар юлларны тутырган.
Безнең капка каршына
Биек тау ясап куйган.

Саф һавада уйнармын,
Тауда чана шуармын.
Җәйгә кадәр үземә
Бик күп көчләр җыярмын.

***Гайнуллин Шәфәгать,***
***6 нчы сыйныф укучысы***

